

Барыбыз да диярлек Яна 2025 елны котәбез, әзерлек эшләре алып барабыз. Темников районы Тархан авылы клубына чыршы алып килгәннәр, бина тәрәзәләрен vзләре ясаган карчыклар белән бизәгәннәр.
Ә Митрялы авылы китапханәсе, авыл клубы белән берлектә “Яна ел чыршысы янында кунакта!” чарасы vткәргәннәр. Программада уеннар, конкурслар, табышмаклар бар иде.

Торле тостәге, ялтырап торган гирляндалар һәм бизәкле чыршы балаларга могжиза тудырды. Кыш бабай белән Кар кызы килv белән чыршы тирәли жыр-биюләр, әйлән-бәйлән уйнау белән чын бәйрәм башланды. Тамашадан сон барлык балаларга Ялышевлар Шәрифжан Рәшит улы белән Гулия Алимжан кызы, Ялышевлар Ринат Хәлим улы белән Зульфия Шәрифжан кызы бvләкләр тапшырдылар; аларга зур рәхмәт белдерәләр.
Балалар бәйрәм кәефе һәм тылсым тойгысы белән кvнел ачканнар.
Тагы Ләмберәнен “Алмаз” мәдәни vзәгендәге Яна ел чыршысы әйләнәсендә “Әни, әти, мин - тату гаилә!” дигән Гаилә елы тәмамлануга багышланган чара vткән. Балалар әниләре, әтиләре, “Алмаз” хезмәткәрләре артистлары белән бергә кызыклы һәм кvнелле чарада бергәләп рәхәтләнеп ял иткәннәр.